ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

23.05.2018 | г. Иннополис | № 34

Иннополис шәһәре көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны оештыру һәм уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Иннополис шәһәре көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны үз вакытында әзерләү һәм уздыру максатларында Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елның 9 июнендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә Иннополис шәһәре көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрергә (алга таба - Чара).
2. Чараны үткәрү планын расларга (1 нче кушымта).
3. Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр, иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләренә Чараны әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.
4. Иннополис шәһәрендә яшәүчеләр арасында булачак чараларны анонслаштыруны тәэмин итәргә.
5. 7 көн эчендә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/) урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р. Р. Шагалиев

Иннополис шәһәре Башкарма
комитеты
№ 34 23 май 2018 ел карарына
1 нче кушымта

2018 елда Иннополис шәһәре көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрү планы.

1. 18:00 Иннополис шәһәре халкын Иннополис Университеты янындагы мәйданда җыю. Интерактив мәйданчыклар эшли башлау.
2. 18:30 - 23:00 Бәйрәм концерты. ( кавер поп-төркемнең һәм кавер рок-төркемнең чыгышы).
3. 23:00 Бәйрәм салюты.